КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 15 гыйнвар г.Казань № 7

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы коллегиясе составын раслау турында» 2013 ел, 2 февраль, 67 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы коллегиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы коллегиясе составын раслау турында» 2013 ел, 2 февраль, 67 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 11 сентябрь, 662 нче, 2018 ел, 30 апрель, 308 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы коллегиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

коллегия составыннан Р.И Вәлиевны, Г.З.Габдрахманованы, С.А Осиповны, Л.О.Сулиманы чыгарырга;

коллегия составына кертергә:

| | |
|---|---|
| Абашев Альмир Рәшид улын | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасарын |
| Әсәдуллина Алсу Мөниб кызын | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасарын |
| Гречанникова Наталья Вадимовнаны | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары – Татарстан Республикасы Мәгариф |

| | |
|---|---|
| | һәм фән министрлыгының Мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаменты җитәкчесен |
| Зарипов Айрат Ринат улын | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисен (килешү буенча); |

Выборнов Андрей Андреевич вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының югары, урта һөнәри белем бирү һәм фән бүлеге башлыгы»;

Шәйхетдинов Хәлил Хәмит улы вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы спорт министрының беренче урынбасары».

Премьер-министр
Республики Татарстан А.В.Песошин